КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 10 март г.Казань № б-408

Татарстан Республикасы халкын авыл хуҗалыгы продукциясе һәм көндәлек кирәкле азык-төлек товарлары белән тәэмин итү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2026 елның 14 мартыннан 26 апреленә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары тарафыннан атна саен махсус билгеләнгән территорияләрдә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек кулланыштагы азык-төлек товарларын сату буенча ярминкәләр (алга таба – ярминкә) үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары башлыклары белән берлектә, ярминкәләр үткәрү урыннарына авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек кулланыштагы азык-төлек товарларын алып килүне тәэмин итәргә;

2026 елның 10 апреленә кадәр авыл хуҗалыгы ярминкәләрен оештыруда катнашкан хезмәткәрләрне һәм вазыйфаи затларны бүләкләү турында нигезләмә әзерләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

атна саен ярминкәләр үткәрү урыннарын билгеләүне һәм әлеге урыннарда сәүдә итү өчен шартлар тудыруны тәэмин итүне;

ярминкәләр үткәрү урыннарында иҗтимагый иминлекне, җәмәгать тәртибен һәм террорчылыкка каршы көрәшне тәэмин итү өчен, шул исәптән хосусый саклау оешмалары хезмәткәрләрен җәлеп итеп, кирәкле чаралар күрүне.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә ярминкәләр үткәрү урыннарында терлекчелек продукциясен алып килүне һәм сатуны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына җәмәгать тәртибен һәм гражданнарның иминлеген тәэмин итү өчен тышкы нарядларны ярминкәләр үткәрү урыннарына якынайтуны;

Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә ярминкәләр уздыру урыннарында азык-төлек продуктларын сату шартларына мониторинг уздыруны.

6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында ярминкәләр үткәрү барышын яктыртуны тәэмин итәргә.

7. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М.А.Җәббаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин